

# Әдәби укудан презентация



# Рәшит Бәшәр 1949

# Шагыйрьнең тормыш юлы



- **Тормыш юлы**
- Рәшит Бәшәр 1949 елның 7 октябрендә Кукмара районы Янил авылында туган. 1972 елда Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң, Татарстанның Лениногорск районы Куакбаш сигезьеллык мәктәбендә балалар укыта, шәһәр профтехучилищесында директор урынбасары, заводта мастер булып эшли.
- 1979 елда Чаллы каласына күчеп килә. КамАЗ заводларында диспетчер, оператор була.
- 1987-1989 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый. Тәмамлап кайткач, «Таң йолдызы» гәзитендә бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип, КамАЗ нәшриятында мөхәррир, «Аргамак» журналында бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип вазифаларын башкара.
- Беренче шигырьләре мәктәптә укыганда ук басыла башлый. «Яшь ленинчы» гәзите, «Ялкын» журналы оештырган әдәби конкурсларда берничә тапкыр җиңеп чыга.
- 1985 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.
- Э. Касыймов, С. Сөләйманова исемендәге әдәби бүләкләр иясе.
- 2000 елда иҗаты Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш бүләгенә лаек булды.

# Шагыйрь гаиләсе белән







# Нәшриятта һәм журналларда басылган әсәрләре

- ***<u>Татар телендә</u>***
- **Әйлән-бәйлән.** Шигырьләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1975.
- **Бәйрәм.** Шигырьләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1977.
- **Яшел океан.** Шигырьләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1981.
- **Ак әкият.** Шигырьләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1986.
- **Иртәгә дә яшисе бар.** Повестьлар. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1989.
- **Ай кызының зәңгәр чиләге.** Шигырьләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1990.
- **Сандугачлы бишек.** Шигырьләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2000.
- **Ачык капка.** Повесть. «Ялкын» журналы, № 2-5, 1989.
- **Акбалык,** Повесть. «Ялкын» журналы, № 6-9, 1993.
- **Бер өйдә җиде кеше. Повесть.** «Аргамак» журналы, №4-5, 1994.
- **Минем әтиемне сугышта үтерделәр.** Повесть. «Аргамак» журналы, № 2, 1996.
- **Акбүре һәм сипкелле малай.** Кыйсса. «Аргамак» журналы, №2, 1997.
- **Изге этләр.** Киноновелла. «Аргамак» журналы, № 11-12. 1998.
- ***<u>Рус телендә</u>*** **Моего папу убили на вой-**
- **не.** Повесть. Мансур Сафин тәрҗемәсе. «Аргамак» журналы, №10,1996.
- **Гаилә кочагында. 2001.**



# Төп темалары:

Туган ил,
дуслык,
хезмәт,
милли йолалар,
гаделлек, табигатьнең матурлыгы һ.б.


ББК 84(2Рос=Тат)-4
Б90
27886
Рәшит Бәшәр
Ачык капка




РӘШИТ БӘШӘР
Сандугачлы бишек


ББК 91.9:83+84(2Рос=Тат)6
Д20
БАЛАЧАК ӘДИПЛӘРЕ
24690
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ


Рәшит Бәшәр
ИРТӘГӘ ДӘ
ЯШИСЕ
БАР




РӘШИТ БӘШӘР
АЙ ҠЫЗЫНЫҢ
ЗӘҢГӘР ЧИЛӘГЕ


ББК 84(2Рос=Тат)-5
Б90
Рәшит Бәшәр
Йолдызлы тай
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ



Хатлар укыганда





# Якташыбыз - шагыйрь Рәшит Бәшәр белән очраштык

**К**укмара 2нче урта мәктәбендә районыбызның Янил авылында туып үскән, хәзерге вакытта Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче балалар язучысы Рәшит Бәшәр белән очрашу булды. Укучылар бу көнне Рәшит Бәшәрнең шигырьләрен укыдылар, аңа үзләренең сорауларын бирделәр.

**- Сез ничә яшегездә яза башладыгыз?**

*- Җиде яшьтә "Коега төшеп киткән ай" турында шигырь яздым. Беренче шигырьләрем район газетасы "Хезмәт даны"ңды басылып чыкты.*

**- Ни өчен Сез нәкъ менә балалар өчен шигырьләр язасыз...**

*- Яшь чакта балалар турында язармын дип һич тә уйламаган идем. Мәктәптә укыта башлагач, балалар белән аралашкач, яшьләр өчен болай да күп язалар, ә балалар өчен язучы юк дип, иҗатымны балаларга багышларга уйладым. Балаларга дип язсам да, аларны олылар да яратып укыйлар. Минем максат: баланы алдамаска, тормышны ничек бар, шулай күрсәтергә - бөтен кырыслыгы, бөтен авырлыгы белән. Мин беркайчан да нәрсә языйм микән дип аптырап тормыйм. Үземнең янәшә-тирәмдәге кешеләр геройлар булып әсәрләргә киләләр дә керәләр. Иҗат иткәндә тормыш тәҗрибәсенә нигезләнәм.*

**- Төрле очрашу-кичәләрдә шигырьләрегезне яттан укыйсызмы?**

*- Күп кенә шигырьләремне яттан беләм.*

**- Шигырьне тәүлекнең кайсы вакытындарак язасыз?**

*- Шигырь ул кинәт туа. Я ул урамнан барганда, я автобуста. Бервакыт йокларга яткач күңелгә шигырь килде. Тордым да тиз генә язып куйдым, барып яттым. Берзаман тагын шигырь килә күңелгә, тагын торып яздым. Шулай бер төн эчендә әллә ничә шигырь туды.*

**- Сезнең өчен шигырь язу нәрсә ул?**

*- Шигырь белән, әдәбият белән яшәү ул минем һөнәрем. Кемнәрдер аңа шөгыль кебек кенә карый, чөнки хәзерге вакытта китап чыгару авыр һәм күпләр иҗат эшен ташлый. Мин бу китап кайчан басылып чыгар дип уйлап тормыйм, язам да язам, барыбер бер чыгар әле дим.*

**- Бүгенге балаларның киләчәген ничек күз алдыгызга китерәсез?**

*- Киләчәк үзегезгә бәйле. Бәхетне акчада гына күреп, рәхәт тормышка кызыгып, барыбер бәхетле булып булмый. Үзебезнең гореф-гадәтләребезне саклагыз! Татар телен онытмагыз! Алга барган кеше барыбер теләгенә ирешә.*

**- Күптән түгел генә РФ Дәүләт Думасына депутатлар сайладылар. Ничек уйлыйсыз, киләчәктә тормыш яхшыга таба үзгәрерме?**

*- Аңысы инде җитәкчеләрдән тора. М.Шәймиевның дөрес сәясәт алып баруы нәтиҗәсендә Татарстан әлегәчә яшь.*

**- Латин графикасына карата мөнәсәбәтегез ничек? Аны кабул итеп кириллицада язылган әдәбият юкка чыкмасмы?**

*- Латин графикасы кирәкле әйбер. Аңа күчеп кенә без надан калмыйбыз. Ләкин бу хәл тиз генә булмаячак.*

**- Мәктәпләрдә татар телен тиешле дәрәҗәдә укыталар дип уйлыйсызмы?**

*- Шәһәр мәктәпләрендә тиешле дәрәҗәдә ук дип уйламыйм, чөнки татар теле укытучылары җитми. Ә менә район, авыл мәктәпләрендә тиешле дәрәҗәдә дип уйлыйм. Моны белү өчен бары тик районнан ничә язучы, шагыйрь чыкканын әйтү дә җитә. Әгәр дә алар 7-8дән артык икән, димәк, татар теле һәм әдәбияты тиешенчә укытылган. Күп нәрсә үзегездән тора. Әдәбиятны укыгыз, яратыгыз! Күп укысагыз, фикерләргә дә өйрәнерсез.*

Инде аерылырга да вакыт, чөнки дәрескә кыңгырау шалтырады. Әле тагын нинди сорауларга җавап аласы калды кебек. Ул сорауларны инде икенче очрашканда бирербез.

**Айгөл ГӨСЕЙНОВА,**
**Кукмара, 2нче урта мәктәп,**
**10нчы сыйныф.**





## Рәшит Бәшәр





### Тәмле шигырь

Тәмле сүзләр бик күп ул:
Вафли, шикәр, шоколад.
Тәмле мультфильм карыйм,
Шоколадны капкалап.
Бал кортлары, күр әле,
Бал ташыйлар тыз да быз,
Бал ашыйлар тыз да быз.
Мультфильм бетеп китте,
Балланып калды авыз.
Бабам белән инде без
Тәмле шигырь язабыз.

«Әни» сүзе дә тәмле,
«Әти» сүзе дә тәмле.
Әби, бабай янәшә -
Өебездә бик ямьле!

«Ватан» сүзе дә тәмле,
«Өй» сүзе дә бик тәмле.
Бакчадагы сыерчык
Оясы да бик ямьле!

Кара ипи дә тәмле,
Ак күмәч тә бик тәмле.
Кояшлы көн, айлы төн -
Икесе дә бик ямьле!»

Язылып бетте шигырь.
Һаман сүзләр уйлыйм мин.
Җитте, җитте...
Шигырьгә
Баллы нокта куйыйм мин.

Мияулаша песиләр:
- Без тәмлегә өйрәндек!
Һәрберсенә аларның
Бирәм баллы перәннек.

Алтмышка җиткән бабам
Минем белән бергәләп,
Шаяргалап, көлгәләп,
Калакны ялап-ялап,
Чәй эчә баллап-баллап.

### Безнең ишегалды

*Бүрәнәдә утыра мәче,*
*Берәр чыпчык эләктермәкче.*

*Әрле-бирле йөргәли бер эт,*
*Ара-тирә өргәли бер эт.*

*Мәче күрсәтте дә тел әткә,*
*Бик тиз кереп китте келәткә.*

*Йә инде, мәче, иренмәче,*
*Тычканың белән күрен, мәче!*









### Сипкелле яз

*Яшел чирәмгә сары*
*Бәбкәләр сипкәләнгән –*
*Чирәмлек сипкелләнгән.*

*Ата каз сөенечтән*
*Биеп тора тып та тып,*
*Булмый аны туктатып.*

*Сөйкемле бер кыз килә*
*Чирәмгә вак-вак басып,*
*Сап-сары бәбкә тотып.*

*Сипкелле малай көлә*
*Тал арасында качып*
*Торганын да онытып.*





### Кошоя

*Очып китте кош бая...*
*Бушап калды кошоя.*

*Кошсыз калган буш оя*
*Күккә карап уш җыя.*

*Суынган буш ояга*
*Буш оя – кошояга*
*Дер-дер килеп һәм өшеп*
*Бер яфрак кунды төшеп.*





- **Бүләкләре:**

- Абдулла Алиш исемендәге бүләк лауреаты(2000)
- Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (1885)
- Э. Касыймов, С. Сөләйманова исемендәге әдәби бүләкләр иясе



# Шагыйрь турында

- РӘШИТ Бәшәрнең көчле ягы - әйләнә - тирәне рәссамча күрә, табигатькә җан өрә белүендә һәм бигрәк тә балалар күңелен аңлый, дөньяга алар күзе белән карый белүендә.

  *Саҗидә Сөләйманова, шагыйрә. 1975*
- Рәшит Бәшәр шигърияте тулысынча сурәтлелеккә нигезләнгән. Тере, якты, хыялый төсләрдә сурәтләнгән табигать, балачак күренешләрендә, әлбәттә, нәни героебызның якыннарына, дус - ишләренә дә урын җитәрлек.
- Аның үз гаме, үз кыйбласы - Балачак иле. Ихлас, иманлы, талантлы каләме һаман нык тоемчан һәм игелекле.

  *Галимҗан Гыйльманов, язучы. 2000*



# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!